**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 16 декабрендәге 5180 номерлы карары**

**Яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел»**
**шәһәр конкурсын уздыру турында**

Туризм индустриясе предприятиеләрен, Казан шәһәре халкын һәм туристларны шәһәр мохитен төзекләндерү һәм камилләштерү буенча уртак эшкә җәлеп итү, тормыш сыйфатын яхшырту, шулай ук туристлык базарында Казан шәһәренең җәлеп итүчәнлеген арттыру максатыннан **карар бирәм**:

1. «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (Д.А.Санникова) Яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын оештыру, координацияләү һәм үткәрүне контрольдә тоту чараларын уздыруга вәкаләтләр бирергә.
2. «Казан шәһәре иҗтимагый үзәге» муниципаль казна учреждениесенә (Е.С.Ямбаршева) Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) тавыш бирүне урнаштырырга.
3. Расларга:

3.1. Әлеге карарга 1 номерлы кушымта нигезендә яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын уздыру тәртибе турында нигезләмәне;

3.2. Әлеге карарга 2 номерлы кушымта нигезендә яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составын.

4. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 6 декабрендәге 3888 номерлы «Яңа ел бизәлеше буенча “Казанда – Яңа ел” шәһәр конкурсын уздыру турында»гы, 2024 елның 26 гыйнварындагы 231 номерлы «Казан шәһәре Башкарма комитетының 2023 елның 6 декабрендәге 3888 номерлы «Яңа ел бизәлеше буенча “Казанда – Яңа ел” шәһәр конкурсын уздыру турында»гы

карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы карарларын гамәлдән чыккан дип танырга.

5. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Аппараты җитәкчесе Б.Р.Алиевкә йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 декабрендәге
5180 номерлы карарына
1 номерлы кушымта

**Яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын уздыру тәртибе турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге нигезләмә яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын (алга таба – Конкурс) уздыру тәртибен җайга сала, Конкурсның максатларын һәм бурычларын, аны оештыру һәм уздыру вакытларын, анда катнашу шартларын, катнашу өчен гаризалар бирү тәртибен, Конкурс буенча сайлап алу һәм Конкурс җиңүчеләрен бүләкләү тәртибен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесе (алга таба – Конкурсны оештыручы).

## II. Конкурсның бурычлары

Кунакчыллык индустриясе предприятиеләрен, туристларны һәм Казан шәһәре халкын шәһәр мохитен төзекләндерү һәм камилләштерү эшенә бердәм рәвештә җәлеп итү Конкурсның төп максаты булып тора.

Конкурсның төп бурычлары:

- үз эшчәнлеген Казан шәһәре территориясендә гамәлгә ашыра торган кунакчыллык индустриясе предприятиеләрен һәм оешмаларын шәһәрне 2024-2025 елгы Яңа ел бәйрәменә багышланган бәйрәмчә бизәүдә катнашуга җәлеп итү;
- кунакчыллык индустриясе объектларының социаль активлыгын һәм инициативасын арттыру, аларны шәһәр проектларына җәлеп итү;
- ял итүнең яңа формаларын булдыру, туристларның һәм шәһәр халкының иҗади мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;
- җәмәгатьчелектә шәһәр территориясен төзекләндерү буенча уңай фикер формалаштыру.

## III. Конкурс этаплары

3.1. Конкурс 2 этапта уздырыла.

I этап – 2024 елның 15 декабреннән 2025 елның 15 гыйнварына кадәр: Конкурста катнашуга объектның атамасы һәм аның урнашу адресы күрсәтелгән, бәйрәмчә бизәлешле объектның фотосурәте яисә видеороликы (номинациягә бәйле рәвештә) беркетелгән гаризалар кабул итү. Гаризаларны tourism.kzn@tatar.ru электрон почтасына җибәрергә кирәк.

II этап – 2025 елның 27 гыйнварыннан 10 февраленә кадәр: Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында тавыш бирү (www.kzn.ru).

3.2. Конкурс нәтиҗәләре җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында игълан ителә, шулай ук 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) бастырыла.

## IV. Конкурста катнашучылар

4.1. Конкурста катнашучылар – конкурс эше сыйфатында капиталь объектны (керү урынын, бинаны) яки эчке интерьерны комплекслы рәвештә бизәгән, туристлык өлкәсендә үз эшчәнлеген Казан шәһәре территориясендә гамәлгә ашыра торган барлык милек формаларындагы предприятиеләр һәм оешмалар, шәхси эшмәкәрләр.

4.2. «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» махсус номинациясендә әлеге нигезләмәнең 4.1 пунктында күрсәтелгән катнашучылардан тыш, номинациядә катнашырга теләүче эшкә сәләтле балигъ яшьтәге физик затлар яисә 14 яшькә җиткән һәм законлы вәкил тарафыннан тәкъдим ителгән физик затлар катнаша алалар.

4.3. Тавыш бирүдә катнашучылар – предприятиеләр һәм оешмалар, иҗтимагый берләшмәләр, инициатив төркемнәр, Казан шәһәре халкы һәм кунаклары.

## V. Конкурсның төп номинацияләре

5.1. Конкурс түбәндәге номинацияләр буенча үткәрелә:

- «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина»;
- «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина»;

- «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина»;

- «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина».

5.2. Әлеге нигезләмәнең 5.1 пунктында күрсәтелгән номинацияләрдән тыш, Конкурс «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» махсус номинациясе буенча уздырыла.

5.3. «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина» һәм «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина» номинацияләрендә катнашу өчен катнашучылар фасадлары Яңа ел стилистикасында бизәлгән биналарның фотосурәтләрен тапшыралар.

5.4. «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» һәм «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» номинацияләрендә катнашу өчен катнашучылар бинаның Яңа ел стилистикасында бизәлгән эчке бүлмәләренең 1 минуттан артмаган видеороликларын тапшыралар.

5.5. «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» номинациясендә катнашу өчен катнашучылар Казан шәһәренең Яңа ел стилистикасында төшерелгән фотоларын (шәһәрнең матур күренешләре; шәһәрнең истәлекле урыннары; шәһәрнең сәнгатьчә пейзажлары) тапшыралар.

5.6. Конкурсны оештыручының, гаризалар кабул ителә башлаганчы, өстәмә номинацияләр булдыру хокукы бар.

## VI. Гаризалар бирү, катнашучыларны теркәү тәртибе

6.1. Комплекслы яңа ел бизәлеше дигәндә төрле элементларны (яктылык җиһазлары, яңа ел уенчыклары, кече архитектура формалары, ылыслы агачлар яки ясалма чыршылар һ.б.) һәм бизәү алымнарын (бина, витрина, керү урыннары, агачлар һ.б.) куллану күздә тотыла. Объектларны Яңа елга бизәгәндә Казан шәһәренең туристлык фирма айдентикасын куллану хуплана.

6.2. Конкурста катнашу өчен Конкурсны оештыручының электрон почтасына tourism.kzn@tatar.ru 2025 елның 15 гыйнварына кадәр, әлеге нигезләмәнең VII бүлегендә күрсәтелгән таләпләрне исәпкә алып, объектның фотосурәте яисә видеоролигы белән гариза-анкета (әлеге нигезләмәгә 1 номерлы кушымта) җибәрергә кирәк.

6.2.1. Фотосурәткә яисә видеороликка өстәмә рәвештә объектның атамасы һәм адресы күрсәтелә.

6.2.2. Һәр катнашучы Конкурска күп дигәндә 5 фотосурәт һәм 1 видеоролик (номинациягә бәйле рәвештә) тәкъдим итә ала.

6.3. Яңа елга бизәлгән объектларның фотосурәтләре номинациягә бәйле рәвештә объект хуҗалары, бизәлеш авторлары, шулай ук Казан халкы яки кунаклары тарафыннан да җибәрелә ала.

Катнашучылар, Конкурста катнашуга гаризалар җибәреп, Конкурс шартлары белән килешүләрен белдерәләр, шул исәптән авторлык эшләрен Россия Федерациясе территориясендә һәм аннан читтә Конкурсны оештыручының мәгълүмати материалларында (социаль челтәрләрне һәм Интернет челтәрен дә кертеп) бастырып чыгару һәм урнаштыру максатыннан Конкурсны оештыручыга вакыты чикләнмәгән гади үзенчәлекле булмаган лицензия шартларында фотосурәтләрдән һәм видеороликлардан файдалану хокукын бирәләр.

6.4. Бәйрәмчә бизәлеш буенча иң яхшы идеяләр Конкурсны оештыручының телеграм-каналында, «ВКонтакте» һәм «Одноклассники» социаль челтәрләрендәге аккаунтларда – gokazan.ru #НовогодняяКазань, #ChristmasKazan, #айдаКазань, #всевКазань, #вказаниесть, #WelcometoKazan, #KazanIsMuchMore хештеглары белән урнаштырыла.

## VII. Конкурста катнашу өчен тапшырылган эшләргә таләпләр

7.1. Фотосурәткә карата таләпләр:

- шәһәрнең яңа ел иллюминацияләре, кышкы пейзажлар, истәлекле урыннар, Казан шәһәренең туристлык һәм популяр урыннары сурәтләгән фотосурәтләр;
- бары тик шәхси фотосурәтләр яисә шәхси архивтан фотосурәтләр;
- әлеге нигезләмәнең 7.1.5 пунктында күрсәтелгән техник таләпләргә җавап бирә торган фотосурәтләр.

7.1.2. Конкурста катнашуга кабул ителми:

- Конкурста катнашмый торган башка автор тарафыннан башкарылган фотосурәтләр;
- ачык кулланылышта, шул исәптән Интернет челтәрендә булган фотосурәтләр;

- әхлак һәм этика нормаларын боза торган, теләсә нинди билге буенча дин тотучыларның хисләрен кимсетә торган яки төркемнәрне дискриминацияли торган фотосурәтләр.

7.1.3. Конкурста 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законны боза торган фотосурәтләр куллану рөхсәт ителми.

7.1.4. Конкурсны оештыручы өченче затларның авторлык хокукларын бозган өчен җаваплы түгел. Тапшырылган фотосурәтләрнең авторлык хокуклары өчен әлеге эшләрне тапшырган Конкурста катнашучылар җаваплы.

7.1.5. Конкурста катнашучы фотосурәтләргә техник таләпләр:

- фотосурәтнең имзасы (атамасы) булырга тиеш (буш урыннарны да кертеп, 50 дән артык булмаган басма билге);
- фотосурәт файлының рөхсәт ителгән форматы – югары сыйфатлы JPEG (*.jpg);
- сурәтнең максималь зурлыгы, киң як буйлап – 1600 пиксель;
- һәр фотосурәтнең рөхсәт ителгән күләме – 5 Мб артык түгел;
- фотосурәтнең сыйфатын яхшырту максатыннан фотосурәтне әз генә эшкәртү, шул исәптән кызыл күзләр эффектын киметү, төсне камилләштерү, кискенлек дәрәҗәсен көйләү һәм башка эшкәртү инструментларын куллану рөхсәт ителә.

7.2. Видеороликка карата таләпләр:

- видеоролик смартфонга да, профессиональ видеокамерага да төшерелергә мөмкин;
- бер катнашучыдан/автордан бер эш кенә кабул ителә;
- видеороликта әдәпсез сүзләр булырга тиеш түгел;
- видеоролик төшерү өчен киңәш ителә торган форматлар: mp4, mpeg, avi;
- якларның нисбәте – 16:9;
- видеоязмаларны иң югары төгәллектә һәм иң яхшы сыйфатта 1 минуттан 5 минутка кадәр озынлыкта өстәргә кирәк;
- аудиокодек – MPEG Layer II яисә Dolby AC-3;
- аудионың битрейты – 128 кбит/с яисә югарырак;
- видеокодек – H.264;
- аудиокодек – AAC;
- видеоның башлангыч ешлыгы секундына 24 тән 30 кадрга кадәр булырга тиеш;
- Конкурска реклама характерындагы, башка кешеләрнең абруен һәм

хисләрен кимсетә торган, Конкурс тематикасына туры килми торган, кеше гомере өчен куркыныч шартларда төшерелгән, шулай ук авторлык хокукларын бозып әзерләнгән һәм элегрәк басылып чыккан роликлар кабул ителми.

## VIII. Конкурс комиссиясе

8.1. Гаризаларны карап тикшерү өчен Конкурсны оештыручы, Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе, Мәдәният идарәсе, Тышкы төзекләндерү комитеты, Кулланучылар базары комитеты, район администрацияләре вәкилләреннән конкурс комиссиясе төзелә.

8.2. «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» Конкурсы номинацияләрендә җиңүчеләр Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) онлайн-режимда үткәрелә торган тавыш бирү нәтиҗәләре буенча билгеләнә.

8.3. Конкурсның «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» номинацияләрендә җиңүчеләр әлеге нигезләмәгә 2 номерлы кушымтадагы бәяләү критерийлары буенча Конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

8.4. Конкурс комиссиясе үз көче белән һәм үз вәкаләтләре кысаларында тапшырылган материаллардагы мәгълүматның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерә. Конкурста катнашу өчен бирелгән гаризада ялган яисә дөрес булмаган белешмәләр, шулай ук гамәлдәге законнарга каршы килә торган мәгълүмат ачыкланган очракта, мондый гаризалар карап тикшерелми.

8.5. Конкурс комиссиясе әгъзасының җиңүчене билгеләгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булган турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган шәхси кызыксынуы барлыкка килгән очракта, ул, конкурс комиссиясе утырышы башланганчы бу хакта конкурс комиссиясе рәисенә хәбәр итәргә тиеш. Мондый очракта конкурс комиссиясенең әлеге әгъзасы конкурс комиссиясе утырышында катнашмый.

8.6. Конкурс комиссиясе карары катгый һәм үзгәртелми.

8.7. Конкурс комиссиясенең конкурска нәтиҗә ясау турындагы карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан раслана.

## IX. Конкурста җиңүчеләрне билгеләү тәртибе

9.1. Конкурс нәтиҗәләре буенча түбәндәге номинацияләр буенча җиңүчеләр билгеләнә: «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» һәм «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш».

9.2. «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» номинацияләрендә Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) тавыш бирү нәтиҗәсендә иң күп тавыш җыйган катнашучылар җиңүче була.

9.3. «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» һәм «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» номинацияләрендә җиңүчеләрне Конкурс комиссиясе билгели.

9.4. Конкурс таләпләренә һәм шартларына туры килә торган катнашучылар конкурс комиссиясе тарафыннан эшләгән бәяләү кәгазьләре нигезендә конкурс комиссиясе тарафыннан 10 баллы шкала буенча бәяләнә (әлеге нигезләмәгә 2 номерлы кушымта).

9.5. Катнашучының рейтингы конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан куелган баллар суммасына тигез.

9.6. «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» һәм «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» номинацияләрендә җиңүче дип иң күп балл җыйган конкурста катнашучылар таныла.

9.7. Конкурс номинацияләрендә җиңүчеләрне ачыклаганда тавышлар саны тигез булса, конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч булып санала.

9.8. Конкурс нәтиҗәләре һәр номинация буенча беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча имзалана.

9.9. Конкурсны оештыручы Конкурс нәтиҗәләрен Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча бастырып чыгара.

## X. Катнашучыларны бүләкләү

10.1. Конкурс нәтиҗәләре буенча түбәндәге номинацияләрдә I, II, III урыннар бирелә:

- «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина»;
- «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина»;
- «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина»;
- «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина»;
- «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш».

10.2. «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Шәһәр халкы тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» һәм «Эксперт жюри тарафыннан кышкы Казан буенча сайлап алынган иң яхшы фотоэш» номинацияләрендә I, II, III урыннар алган катнашучылар Казан шәһәре Мэры дипломнары белән бүләкләнәләр.

10.3. «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы бизәлгән бина», «Эксперт жюри тарафыннан сайлап алынган Яңа елга иң яхшы эчтән бизәлгән бина» номинацияләрендә җиңүчеләр өстәмә рәвештә 50 000 сум күләмендә акчалата призлар белән бүләкләнә.

10.4. Җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы 2025 елның 28 февраленнән дә соңга калмыйча уздырыла. Конкурста катнашучыларга, тантананы үткәрү вакытына кадәр өч көннән дә соңга калмыйча, Конкурсны оештыручы тарафыннан электрон почта аша бүләкләү тантанасын үткәрү көне һәм урыны турында хәбәр ителә.

---

Яңа ел бизәлеше буенча
«Казанда – Яңа ел» шәһәр
конкурсын уздыру тәртибе
турында нигезләмәгә
1 номерлы кушымта
(Форма)

**Яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» конкурсында катнашуга гариза-анкета**

| | | |
|---|---|---|
| 1 | Гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме | |
| 2 | Элемтә өчен телефон номеры | |
| 3 | E-mail | |
| 4 | Объектның атамасы | |
| 5 | Объектның адресы: | |
| 6 | Номинация | |
| 7 | Фотосурәткә/видеороликка сылтама (номинациягә бәйле рәвештә) | |

______________________________ ______________________________
(тутыру көне) (гариза бирүче имзасы)

## ШӘХСИ МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫ ЭШКӘРТҮГӘ РИЗАЛЫК

Мин, ________________________________________________________________,
(фамилиясе, исеме, атасының исеме тулысынча)

____________________________________________________________________________

________________________________________________________ адресы буенча теркәлгән, шәхесне таныклый торган документ: ____________, сериясе: _____ номеры: ________ бирү көне «_____» _________________, кем тарафыннан бирелгән ________________________________________________________________________,

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 9 статьясы нигезендә «Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Кремль урамы, 11А йорт, 5Н бина) шәхси мәгълүматларымны эшкәртүгә, атап әйткәндә, тормышымдагы фактлар, вакыйгалар һәм хәлләр турындагы мәгълүмат белән 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 3 статьясында каралган гамәлләрне башкаруга ризалык бирәм.

2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль законның 6 статьясы нигезендә мине Казан шәһәре муниципаль бүләкләре белән бүләкләүгә тәкъдим итү максатыннан, шулай ук Казан шәһәре бүләкләре белән бүләкләнгән затлар турында мәгълүматны саклау максатыннан минем тарафымнан 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләре нигезендә эшкәртүгә ризалык бирелгән, тапшырылган шәхси мәгълүматларымны, шул исәптән, фамилия, исеме, атамның исеме, паспорт мәгълүматлары, җенес, яшь, гаилә хәле, элемтә өчен телефон номеры һәм e-mailның һәркем файдалана алырлык дип саналуын сорыйм.

Шәхси мәгълүматларымны эшкәртү 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы «Шәхси мәгълүматлар турында»гы федераль закон таләпләренә тулысынча туры китереп башкарылуы белән килешәм.

Шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыгымның һәм аларның әлеге ризалыкта күрсәтелгән максатлар өчен һәркем файдалана алырлык булуының вакыты чикләнмәгән. Ул мин язма рәвештә аерым боерык чыгарганчы гамәлдә.

_________________________ (тутыру көне)

_________________________ (гариза бирүче имзасы)

Яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын уздыру тәртибе турындагы нигезләмәгә 2 номерлы кушымта
(Форма)

БӘЯЛӘҮ КӘГАЗЕ

Объектның атамасы ________________________________________

| № | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 10 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| 1 | Бизәүнең комплекслылыгы | | |
| 2 | Стиль ягыннан чишелеш һәм гомуми гармония | | |
| 3 | Проект карарларының функциональлеге һәм нәтиҗәлелеге | | |
| 4 | Стандарт булмаган карарларны, алдынгы материалларны һәм технологияләрне, заманча тенденцияләрне куллану | | |
| 5 | Казанның үзенчәлеге һәм танылу чагылышы | | |

Комиссия әгъзасы ____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

Комиссия әгъзасы имзасы ____________________________________________

Тутыру көне ____________________________________________________

«ЭКСПЕРТ ЖЮРИ ТАРАФЫННАН КЫШКЫ КАЗАН БУЕНЧА САЙЛАП АЛЫНГАН ИҢ ЯХШЫ ФОТОЭШ» НОМИНАЦИЯСЕНДӘГЕ ЭШНЕҢ БӘЯЛӘҮ КӘГАЗЕ

Авторның фамилиясе, исеме, атасының исеме, эшнең атамасы ___________
_________________________________________________________________

| № | Бәяләү критерие | Бәя (1 дән 10 баллга кадәр) | Ачыклама |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурс тематикасына туры килү | | |
| 2 | Теманы ачуга иҗади якын килү | | |
| 3 | Тәэсирле һәм үзенчәлекле автор алымы | | |
| 4 | Сәнгатьчә һәм эстетик башкару дәрәҗәсе | | |
| 5 | Техник сыйфаты | | |

Комиссия әгъзасы ____________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Комиссия әгъзасы имзасы ____________________________________________

Тутыру көне ____________________________________________________

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2024 елның 16 декабрендәге
5180 номерлы карарына
2 номерлы кушымта

**Яңа ел бизәлеше буенча «Казанда – Яңа ел» шәһәр конкурсын уздыру буенча конкурс комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Санникова Дарья Александровна | Конкурс комиссиясе рәисе, Казан шәһәренең туризмны үстерү комитеты директоры |
| Сәлмәнова Гүзәл Әсгать кызы | комиссия сәркатибе, Казан шәһәре туризмны үстерү комитетының баш эксперты |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Төхвәтуллина Илсөяр Мисхәт кызы | Казан шәһәренең баш архитекторы |
| Белицкая Жанна Владимировна | Казан шәһәре Башкарма комитетының Архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе башлыгы урынбасары – шәһәр дизайны бүлеге башлыгы |
| Горбунов Алексей Павлович | «Шәһәрне үстерү институты» муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Салихов Альберт Иршат улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгы |
| Фәтхетдинов Роман Рәмиз улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Совет районы администрациясе башлыгы |
| Жаворонков Владимир Владимирович | Казан шәһәре Башкарма комитетының Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе башлыгы |
| Шәмсетдинов Ренат Харрас улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Авиатөзелеш һәм Яңа Савин |

| | |
|---|---|
| | районнары администрациясе башлыгы |
| Фәезов Айрат Шамил улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының «Иске шәһәр» территориясе префекты |
| Абзалов Азат Искәндәр улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе башлыгы |
| Сәлахетдинов Игорь Игоревич | Казан шәһәре Башкарма комитетының Тышкы төзекләндерү комитеты рәисе |
| Фазылҗанов Руслан Фәрит улы | Казан шәһәре Башкарма комитетының Кулланучылар базары комитеты рәисе |